# О происхождение деревни Палагай Юкаменского района Удмуртской АССР

## Страницы недавнего прошлого

Я родился в деревне Палагай Юкаменского района Удмуртии. Мои родители, отец Харис Хабибрахманович Галеев (1898-1961), родом из деревни Табарле современного Агрызского района Татарстана, мать Хамида Сынгатулловна Галеева (урожд. Касимова) (1905-1980), родом из деревни Кестым современного Балезинского района Удмуртии, всю жизнь с 1930 года работали сельскими учителями в этой деревне.

Мне с детства хотелось узнать, когда была основана деревня Палагай, откуда сюда пришли первые жители, какой национальности они были, почему деревню назвали «Палагай». Ближайшая предыстория деревни хорошо известна: до середины 70-х годов прошлого столетия были два Палагая - Большой и Малый, потом их объединили в одну. Но до сих пор Малый Палагай мы называем «Ар як Палагай», то ли потому, что она находится за ручьем Шалькопи-чокыр на склоне довольно крутого южного склона холма, то ли оттого, что первопоселенцами там были удмуртскоязычные бесермяне. Название ручья Шалькопи-чокыр произошло от удмуртского названия рыбы налима шалькко (шалькко пи с удмуртского малек налима).

В переводе от татарского «Ар як» - «Та сторона» (за ручьем, за логом). Татары удмуртов называли этнонимом «ар, арлар», тогда «Ар як» может означать «Удмуртская сторона», местность, деревня за ручьем, логом, где живут удмурты, точнее, удмуртскоязычные жители. По свидетельству ученых этнографов, татарские деревни на средней Чепце, в том числе Палагай и большинство татарских деревень современного Юкаменского района были населены бесермянами, бывшими по глубокому убеждению татарских ученых тюрко (татаро)язычным этносом, и по не менее глубокому убеждению удмуртских этнографов, удмуртскоязычным населением. В XVII-XVIII веках русское правительство начало крещенье удмуртов и бесермян, которых считало язычниками. Но некрещеные бесермяне себя к язычникам не относили, а считали себя правоверными мусульманами. Некрещеные бесермяне не отдавали своих дочерей замуж за крещеных бесермян и удмуртов, но так же не отдавали их и за некрещеных удмуртов, как за иноязычных. Поэтому взрослые юноши крещеных бесермян вынуждены были брать себе в жены девушек из удмуртских деревень и через несколько поколений в их семьях удмуртский язык становился преимущественным и обыденным.

Из архивных документов известно, что еще в 1797 году в деревнях Палагай и Кестым имелись соборные мечети. Строительство мечетей продолжалось во всех татарских деревнях на средней Чепце в продолжение всего XIX и начала XX веков. Но в них проживали не только татары, но и тюрко (татаро)язычные бесермяне, в этом согласны и татарские и удмуртские этнографы. Ясно, что за несколько лет (удмуртско) иноязычных бесермян нельзя было бы так быстро превратить в татароязычных людей.

Хотелось бы предложить читателям одну из возможных предположений возникновения деревни Палагай, появившуюся у меня после знакомства с книгой П.Н. Луппова «Документы по истории Удмуртии XV-XVII веков. Ижевск. 1958». П.Н. Луппов в своей книге опубликовал выписки из дозорных (переписных) книг Чепецких удмуртов, татар, чуваш (бесермян) 1615, 1629, 1646 и 1678 годов (документы №№ 51-61). В документе № 59 записаны деревни Убыть Верхняя, Средняя и Нижняя. Верхняя Убыть и Нижняя Убыть. Эти удмуртские деревни сохранились до настоящего времени, находятся они в Глазовском районе. В этом же документе записаны две пустоши «Ивановская на речке на Убытке», где ранее были зарегистрированы два двора и «Кунасевская на речке на Убытке» с одним двором. В переписной книге указано, что эти дворы пусты, а жители «сошли» в Казанский уезд тому годов с 17 (в 1629 г.). Возможно, в этих населенных пунктах жили тюркоязычные жители (бесермяне или татары), иначе зачем им было бежать в Казанский уезд?

Переписи (ревизии) населения проводились для учета податных душ мужского пола, так как земельными наделами, бортевым лесами, рыбными и охотничьими угодьями наделялись только они, но не «души женского полу».

В документе № 60 «Приставные дворы в Каринской и Верхочепецкой волости у удмуртов и бесермян по переписи 7170 (1662) г. зарегистрирован «Починок Новый выше верхееево Убыти: в/бесермянин Зянбулатко Бекбулатов сын Бедаков поставил во 162 (1654) году, у Зянбулатка 2 сына: Абашко, Тюбачко женаты, у Абашко дети Ищмаметко, Дусмаметко, Ермеметко, Зямаметко» Под «Приставными дворами» в этом документе П.Н. Луппов отмечает крестьянские дворы, выделившиеся из старых дворов и поставленные или в той же деревне, или на вновь расчистных из под леса участках. Переписчики буквой «в/» заменяли понятие «во дворе» (хозяина, домовладельца).

Через 16 лет в 1678 году писцы Михаил Воейков и Федор Прокофьев регистрируют «Починок над речкою Убытью: в/Зянбулатко Бехбулатов сын Бединов, у него внуки Абашевы дети Ешмеметко да Ермеметко женаты, Замаметко 20 лет, Дахтубайко Тубачев сын 15 лет, Бегенко 13 л., Шахмаметко 10 лет». Очевидно, что этот починок принадлежит Бединову (в переписи 1662 года – Бедакову, но это один и тот же человек: переписчики записывали податные души по опросам на слух; отсюда как бы разные фамилии). Хотя с 1654 года прошло 24 года, починок все еще без названия: однодворный починок еще не деревня или за эти годы Бединов (он же Бедаков) менял место жительства своей семьи, или в этой семье произошли важные события. Сравните обе переписи 1662 и 1678 годов. В 1678 году не записаны Абашко и Тюбачко, в перепись попали только их дети. Можно предположить, что в перерыве между двумя переписями его сыновья умерли, оставив своих детей на руках деда. Я склоняюсь к мысли, что Зянбулат все же менял место жительства, и, может быть, дважды: после смерти каждого из сыновей. Он бросал «плохие, дурные» участки и искал лучшие, хорошие места для своей семьи. Мне кажется странным, что к его починку никто не подселяется, хотя за это же время по переписи 1678 года появляется «Починок Тутаев, что подле Убыти», в котором 5 домохозяйств с 22-мя лицами мужского пола.

По воспоминаниям стариков, место первого починка было в урочище Алабаш в 2-3 км выше от устья речки Држина чокыр, левого притока реки Убыть. Даже и сейчас там имеется большое поле под названием «Плешь». По рассказам земляков из Палагая, до сих пор там видны следы построек, когда-то стоявших недалеко от речки. Возможно, это был первый починок Зянбулата. Интересно, что название урочища Алабаш с татарского языка может быть переведено как пестрая голова, или, точнее – седая голова. Зянбулат – первопоселенец - был уже старым человеком, с сильно поседевшей головой и бородой.

На правом берегу Убыти южнее урочища «Нарат Чишмә» на небольшом ровном месте была еще одна небольшая деревня, которую в Палагае до сих пор называют «Эскерт» или «Иске йорт». Мощные родники, вытекающие из глубокого и неширокого лога дали возможность первопоселенцам построить небольшую мельницу с одним станком-крупорушкой. Когда я учился в семилетке (до 1950-х гг), старики нам показали земляную плотину высотой более метра, сохранившуюся до наших дней. В конце XIX века выше урочища «Нарат Чишмә” на северо-западном склоне урочища “Зянбулат тау” на правом берегу Убыти была построена мельница на два постава, просуществовавшая до середины 60-х годов прошлого столетия (в архивных документах мельница упоминается впервые в 1905 году). Эта мельница была построена на паях крестьянами Большого и Малого Палагая и бесермянской деревни Гулекшур. Как видим, имя Зянбулата не потерялось во мраке веков, он оставил его крутой горе, покрытой густым сосновым бором.

Относительно недавно мой земляк Абашев Малик, 1940 г. рождения, рассказал мне, что его дед Каюм Габид улы Абашев (1865-1949), успел показать ему сравнительно ровную полянку в сосновом лесу выше родника «Нарат Чишмә» и рассказал, что здесь было старое кладбище исчезнувшей деревни. Эту полянку, до сих пор не заросшую большими деревьями, я неоднократно посещал, но не знал, что там было в старину. Таким образом, наличие старого кладбища является прямым доказательством, что выше родника некогда была деревня.

Но и это место не понравилось первопоселенцам. Возможно, в этом починке умер или погиб второй сын Зянбулата, и он связал это событие с употреблением «плохой» воды из этого родника, тогда зачем до сих пор жители деревни Палагай не любят пить воду из родника «Нарат Чишмә». В детстве нас, детей, всегда оговаривали и запрещали там брать воду, говоря, что там «ловит» и что мы можем заболеть…

Следующий починок был поставлен ниже родника на расстоянии одного километра по течению Убыти на правом же берегу Убыти на истоке небольшого современного ручья «Баби» вблизи урочища «Поршай». Во время Великой Отечественной войны и многие годы уже после войны, мы, дети, ходили собирать черемуху, рябину и калину, росшую на месте бывшей деревни. Тогда еще были видны ямы подпольев от не менее чем десятка домов, стоявших там. Это место в конце сороковых годов прошлого столетия старики так же называли «Иске йорт», или на местном диалекте «Эскерт». К сожалению, в начале 60-х годов мелиораторы под предлогом расширения полей, выкорчевали все кустарники и заровняли место старой деревни.

По преданиям, в деревне на Поршае из родника ушла вода, вероятно, после вырубки лесов под пашню, и жители опять были вынуждены поменять место жительства. Они нашли мощные ключи почти напротив родника «Нарат Чишмә» на сравнительно небольшом расстоянии на левом берегу Убыти. Основателем деревни мои земляки считают красивую и предприимчивую девушку по имени Палаг или Малаг, по имени которой деревню назвали Палагай. На тюркском, татарском языке ай – луна, ай йөзле кыз - красавица; из татарского языка ай йөзле кыз (как идиома) на другие языки прямо не переводится.

В документах V-й и VI-й ревизий 1795-го и 1811 годов деревня все еще не имеет названия, и переписчики записали новое поселение «Починком у речки Убыти» (ГАКО. Ф. 176, оп. 8, д. 14). В переписи 1811 года в Починке в 18 домохозяйствах живут 86 душ мужского пола, только там появилась новая семья с фамилией Касимовы, потомки которых до настоящего времени проживают в деревне, а коренные жители Палагая почти все носят фамилию Абашев. Итак, можно с уверенностью предположить, что в этом Починке обосновались потомки одного из сыновей Зянбулата Абашко – Абашевы дети.

Только вот что странно: из других архивных документов известно, что в 1794 году по состоянию на 23 июня в ревизской сказке зарегистрирован «Губайдулла Рамазанов сын Касимов, 21 лет из деревни Кестымской <…> у него жена Тутья Баязитова дочь 22 лет, <…> из деревни Палагинской…». (ГАКО. Ф.176, оп. 8, д. 7. Примечание: все архивные справки получены от доцента ГГПИ Д.Г. Касимовой). Почему тогда в V-й и VI-й ревизиях 1795-го и 1811 годов деревня все еще носит название «Починок у речки Убыти»? Весьма вероятно, что под названием деревня Палагинская переписчики зарегистрировали третий починок внуков Зянбулата, а «Починок у речки Убыти» это новое поселение на левом берегу Убыти.

Зянбулат Бединов (или Бедаков), его дети и внуки были бесермянами и, приняв во внимание убежденность удмуртских ученых, что бесермяне изначально были удмуртскоязычным этносом (или с большой компонентой удмуртского языка ), происхождение названия деревня Палагай можно попытаться объяснить следующими рассуждениями.

Попробуем этнотопоним «Палагай» разделить на две части: «пал» и «агай». Первая часть топонима «пал» с удмуртского языка имеет несколько значений и переводится, как «сторона», или половина чего-либо, например, человек с увечьем: без руки или ноги, слепой на один глаз («синпал»).. Так, «палкышно» переводится как «вдова», одинокая женщина, «палпиосмурт» - вдовец, одинокий мужчина. «Агай» означает и на татарском, и на бесермянском языках дядя, дядюшка, (вежливое обращение к старшему мужчине) (не забудем, что по твердому убеждению татарских этнографов, бесермяне являются тюрко (татаро)язычным этносом).

Попробуем собрать слово «Палагай». Читателю я предложу небольшой диалог между двоюродными или родными братьями, один из которых вернулся домой после большой отлучки. Например, к Замаметку Абашева сыну обращается Тахтубайко Тубачев сын с

вопросом: «Ермеметко кытын?» - «Починкае, пал агае доры мыниз», или: «Пал агай починкаяз мыниз». На вопрос: «Где Ермеметко?» - брат отвечает, что он ушел в починок дяди (вдовца, или инвалида, скажем, без руки), ранее основавшего новый починок. Со временем выражение «Пал агай починкаяз мыниз» могло сократиться до «Пал агай починкаяз», а затем сократиться до названия «Палагай» и стать названием нового починка, новой деревни.

И вот уже более двух столетий мои земляки живут в деревне, с начала XIX века всеми переписчиками записываемой под названием (топонимом) «Палагай». Если еще сто лет назад Палагай был с чисто татарским населением, то в настоящее время в деревне живут не только татары, но и удмурты, бесермяне, русские, украинцы, и, наверное, и представители других этносов.



**А. Галеев, пенсионер,**

**Удмурт АССРның Юкаменск төбәге**
**Палагай авылы тарихы**
**Үткән юллар сәхифәләре**

Мин Удмуртияның Юкаменск төбәгендәге Палагай авылында тудым. Ата – аналарым чыгышлары: әтием Татарстан ягыннан Әгерҗе төбәгендәге Тәбәрле, әнием Удмуртияның Балезино төбәгендәге Кистем авылларыннан булсалар да, кайчан нинди милләт вәкилләре авылыбызга нигез салган, атама кушкан кебек сораулардан бала чагымнан ук тынычлыгымны югалттым дисәм, арттыру булмас.

Билгеле ки, 1970 елларның уртасына кадәр ике – Зур һәм Кече Палагай булган. Хәзер дә еш кына Зур Палагайда яшәүчеләр кечесен "Ар як Палагай" дияләр. Дөресенчә, бу ике авыл үз урыннарында ук утыра, тик документлар буенча алар бер авыл – Палагай - дип язылалар. "Ар як Палагай" дип әйткәннең сәбәбе әллә авылның Шалькопи-чокыр исемле кечкенә генә елганың аргы ягында, әллә беренче күчешүчеләрнең ар (удмурт) телле вәкилләре булуы белән бәйләнгән булса кирәк. (Шалькко пи с удмуртского – малек налима). Палагай авылы һәм Юкаменск төбәгендә урнашкан күбесе авыллар нигезләүчеләре гәлимнәр язуы буенча "бисермән" исеме белән аталган төрки яки удмурт телле этник төркеме (таифәсе) булган. XVII –XVIII гасырларда рус хөкүмәте Чүпче елга буенда торган бисермәннәрне, арларны – алар барсы да ул вакытта мәҗүсилектә булганнар – һәм татарларны көчләп чукындыра башлаган. Чукындырылган бисермәннәр ар теленә күчәргә мәҗбүри булганнар: чукындырылмаганнары үзләрен татар дип хис иткәннәр. Аларның авылларында мәчетләр куелалалар, мәсәлән, Киров өлкәсе архивының документлары буенча Палагайда 1797 елда мәчет булганы мәгълүм. Ислам динен тотучылар үзләренең үсеп җиткән кыз балаларын ят динле егетләргә кияүгә бирмәгәннәр, шуңа курә бисермән егетләре ар авылларыннан кыз сорарга мәҗбүр булганнар, бер-ике буыннан соң аларның гаиләләрендә ар теле гади тел булып кала башлый.

Рус галиме П.Н.Лупповның "Документы по истории Удмуртии XV –XVII в.в. Ижевск. 1958.» китабында Чүпче (Чепца) удмуртлары, татарлары, чувашлары (бисермәннәре) арасында 1615, 1629, 1646, 1662 һәм 1678 елларда уткәрелгән халык исәбен алу язулары урын алган (Док. №№ 51 -61).

Убыть елгасы буена беренче күченүләр 1646 ел белән билгеле (Д. № 59, 240 бит). Хәзерге Глазов төбәгенең Югары, Урта, Түбән Убыть авыллары булган, Югары һәм Урта Убыть авыллары бүгенге көннәргә кадәр сакланып калганнар. Хәзер алар ар телле авыллар. Бу ук документларда «Убыть елгасында ике буш хуҗалык Ивановская да, бер буш хуҗалык Кунасевская да язылган, һәм шушы хужалар 17 ел элек каралтыларын ташлап, Казан

өязенә киткәннәр». (Бәлкем, шул авыллардагы торучы гаиләләр татар телле кешеләр булган, нигә дип алар  Казан өязенә  качып китәргә мәҗбүр булганнар?).

Халык хисап язмалары ир-ат җан ияләреннән ясак алу өчен уздырылган (эшләнгән), чөнки ир-ат башына гына имана, балык, ау җирләре, балкортлы урманнары (бортевые угодья)  бирелгән.

60-нчы документта  "Приставные дворы в Каринской и Верхочепецкой волости у удмуртов и бесермян по переписи 7170 (1662) г." (Луппов.1958. 251 бит)   Убытьтан югарырак яңа пүчинкә (починок, починка) күрсәтелгән: бисермән Җанбулатко Бекбулат улы Бедаков 162-нче (1654) елда хуҗалык салган. Җанбулатконың ике улы: Абашко, Тюбачко өйләнгәннәр,  Абашконың балалары Ищмаметко, Дусмаметко, Ермеметко, Зямаметко.

П.Н. Луппов бу документның искәрмәсендә өстәп куелган хуҗалыкларны (приставные дворы) искесеннән аерылып чыгып, шул ук авылда яңа әрчелгән  (эшләнгән) җирдә, яисә туган авылларыннан читкәрәк  салынган (на выселках, починках) крестьян хуҗалыклары дип аңлата.

1678 елны, 16 елдан соң, кучереп язучылар Михаил Воейков һәм Федор Прокофьев Убыть елгасы буенда Җанбулатко Бекбулат улы Бединов хуҗалыгын күрсәтәләр (Д. № 61, 288 бит). Анын оныклары Абаш балалары (Абашевы дети) Ешмеметко, Ермеметко өйләнгәннәр,  Зямаметко 20 яшь;  Дахтубайко Тубач улына 15,  Бегенкога 13, Шахмаметкога 10 яшь.

Мөгаен, бу пүчинкә Бединовныкы булган (беренче хисапта Бедаков дип язылган булса да, бу бер үк кеше, чөнки күчереп язучылар җан ияләрен сүз ишеткән буенча гына язганнар).

1654 елдан башлап 24 ел узса да, пүчинкә атамасыз була, чөнки бер генә хуҗалыклы урын авыл була алмый.

Шулай ук Бединов гаиләсенең тормыш урыннары да алыштыргаланган, яисә бу гаилә кайгылы вакыйгалар  кичергән, ахрысы. Ике язманы чагыштырганда, 1678 елда Абашко һәм Тюбачко  күренмиләр,  балалары гына эләккән. Җанбулатконын уллары үлеп, уз балаларын бабайларына калган дип  , фикер йөртергә  мөмкин, тик болай үзем уйлыйм: Бединов үз урынын ике мәртәбә алыштыра: бер улы үлгәч - бер мәртәбә, тагын бер мәртәбә икенче улы вафат булгач. Бединов "начар" жир участокларын ташлап, яхшырагын эзләгән дигән фикер килә.

Анысы да гажәеп,  24 ел эчендә бу пүчинкәгә башка  гаиләләр урнашмаганнар, ә бит 1678 елны Убыть буенда 3-4 чакрым  югары  юнәлешендә  Тутаев пүчинкәсе килеп чыга, анда 5 хуҗалыкта 22 сан ир-ат язылган була, хатын-кызларны исәпләсәң, анда торучылар, минемчә, 50 гә якын кеше булган. Хәзерге Палагай авылыннан Тутаевога кадәр 5 чакрым санала.

Олылар сөйләүенчә, Палагай авылының беренче  урыны "Алабаш" аймагында (аймак = урочище) булган (бу Убытьтан ике-өч чакрым югарырак,  Држина-чокыр дигән сул култыгы буенда куе урман эчендә  булган;  хәзер дә анда  "Плешь" исемле зур гына басу бар, авылдашлар әйтүе буенча, анда иске йорт урыннары әле дә күренә). Соңыннан Нарат чишмәдән югарырак  урманнан җир әрчегәннән соң,  Җанбулат шунда пүчинкәсен күчерә. Хәзер дә Нарат чишмәсеннән аккан  елгасында  тегермән буасы сакланып калган, мин җидееллык мәктәптә укыганда  (1940-нчы елларның азагы) картлар безгә  анда бер пар ташлы тегермән булган дип, сөйләделәр.  XIX гасырнын азагында Нарат чишмәсенән югары текә тау итәгендә, аның төнъяк–көнбатыш ягында Убытьта тегермән булган  (архив язмалары буенча тегермән 1905 елда эшләгән инде, ул  Зур һәм  Кече  Палагай,  Гулекшур авылларына ике станоклары белән хезмәт иткән). Борынгы бабабыз  Җанбулат үз исемен шул куе наратлы урман белән үскән тауга биреп калдырган дигән риваятьләр Палагай һәм күрше авылларда хәзер дә яши. Шул текә тауны бүген  дә Җанбулат тау дип исемлиләр.

Минем замандашларым  Нарат чишмә һәм Убытьта куелган тегермән арасындагы булган иске авылны "Иске авыл – Иске Йорт – Эскерт" дип әйтәләр. Күптән түгел Каюм Габид улы Абашевның (1865-1949) оныгы Мәлик Садритдин улы Нарат чишмә белән

Җанбулат тау арасында үскән нарат урманының югары башында татар зираты бар, дип сөйләде, ул аймакны аңар Каюм бабае күрсәтеп калдырган. Шулай итеп, Бединовның икенче пүчинкә урыны бу урында булганы дәлил була. Ләкин моннан Җанбулат үзенең гаиләсе белән нигәдер тагын яңа урынга күчәргә мәҗбүр булган. Бәлкем, Нарат чишмә суын борынгы кешеләр "начар су" дип санаганнар: минем бала чагымнан башлап бу көннәргә кадәр авылдашларым Нарат чишмә суын эчәргә яратмыйлар, Нарат чишмә аймагында "тота" дип эчкерсез ышаналар, имеш, бу суны эчсәң, чиргә сабышырсың дип, куркыталар.

Җанбулатның бу яңа авыл урыны "Поршай" аймагына якын урнашкан булган, хәзерге Палагайдан Убытьның су агымыннан ике чакрымда түбәнрәк уң ягындан бер чакрым исәп югарырак тау битендә булган. Бөек Ватан сугышы вакытында һәм соңрак без, балалар, бу иске авыл урынына җиләк җыярга йөри идек. Иске юл буенда бер унлап йорт урыннарында сакланган идән асты базлары тирәсендә куе гына шомырт, миләш, карлыган, гөлҗимеш куаклары үсәләр иде. Менә бу иске авыл урынын картлар кырыгынчы елларның азагында безгә "Эскерт" яки "Иске йорт" атамалы урын дип белдерделәр.

Кызганычка каршы, 1960-нчы елларның башында "сука басуларны киңәйтәбез" дигән ысул белән мелиораторлар җиләк куаклы иске авыл урынын бульдозерлар белән кырып юк иттеләр.

Риваятьләр буенча, Поршай астындагы авылда чишмә сулары беткән һәм авылдашлар Убыть елганың сул ягында бик көчле чишмә янында яңа урын табалар. Бу яңа урын нәк Нарат чишмә каршында бер чакрымнан ким урында булган. Бу яңа авылны нигезләүче Палаг-мы яки Малаг-мы исемле бер чибәр һәм батыр ай йөзле кыз булган дип, сөйлиләр (татар, төрек телләрендә ай – луна, ай йөзле кыз – красавица; на татарском языке – идиома, на другие языки прямо не переводится). Риваятьләр буенча, бу кыз яңа авылга үзенең исемен калдырган имеш, һәм авылны Палагай дип бу кызның исеме буенча исемләгәннәр дип әйтәләр

Төп Палагай халкының барысы да Абашевлар (1811 елгы хисап язулары буенча Палагай булачак урында бер гаилә Касимовлар, хәзер дә аларның токымнары авылда бар). Димәк, бу авылга нигез салучы Абашевларның бер баласы булырга тиеш. Киров өлкәсе архив документлары буенча, V-нче (1795) һәм VI-нче (1811) ревизияләрендә Убыть елгасы янында исемсез пүчинкә булган, 1811 елда бу пүчинкәдә 18 хуҗалыкта 86-га кадәр ир-ат затлары яшәгән. Шунсы кызык, 1794 елдагы бүтән архив документында шулай дип язылган: «Губайдулла Касимов из д. Кестымской ( по состоянию на 23 июня 1794 года), у него жена Тутья Баязитова дочь 22 лет , …из деревни Палагинской» - нишләп 1795 елда Убыть елгасы янындагы пүчинкәнең исеме юк, ә 1794 елда ул ук пүчинкәнең исемен деревня Палагинская дип, язганнар? (Югары язган мәгълүмәтләр Глазов udинститутынын доценты Д.Г.Касимовадан алынган).

Җанбулатко Бедаков (Бединов), аның балалары, оныклары бисермән таифәсеннән булганнар. Шуны V-нче һәм VI-нче ревизиялары раслый: "В починке у речки Убыти служилые некрещенные бесермяне" (ГАКО .Ф.176, оп.8, д. 14, л.л. 9-18. Из архивов Д.Г.Касимовой).

Удмурт галимнәренең фикере буенча бисермәннәр ар телле төркем булганнар (Атаманов. 1988. сс. 17-18) (шунсы кызык, татар галимнәре бисермәннәрне татар–төрек телле таифә дип саныйлар). Удмурт галимнәренең фикерен дөрес дип алсак, Палагай авылының исеме (этнотопонимы) менә болай килеп чыккан дип әйтергә була: бу топонимны икегә бүлик – беренче өлеше "Пал" – удмуртча берничә мәгънә аңлата, берсе "як" дигән сүзне (сторона) яисә нәрсәнең булса да яртысын. "Палкышно" – тол хатын, "палпиосмурт" – тол ир кеше. Икенче яртысы "агай" өлкән туган мәгънәсендә: "дядя = абый = абзый" - ихтирамлы мөгәләмә (вежливое обращение к старшему по возрасту родственнику, мужчине). Хәзер Палагай атамасын "җыеп" карыйк. Кыска гына диалог тәкъдим итәм: Замаметко Абаш улы әле генә ерак юллардан кайтып, Ермеметко абыеннан Тубач улы Дахтубайко абзые турында кызыксына. Замаметко ар телендә аңар: "Починкае, пал агае доры мыниз", яисә "Пал агай починкаяз мыниз" ("Пүчинкәгә тол абзые янына" яисә "Тол абзыеның пүчинкәсенә китте"),

дигән җавап ишетә. Бу пүчинкә Убытьның сул ягында утырткан яңа пүчинкә булырга тиеш. Хәзер Палагай атамасын "җыеп" карыйк: вакытлар узып бу сөйләмәләрдә яңгыраган "Пал агай" сүзләре бергә кушылып "Палагай" дип ишетелә башлаган һәм бу атама яңа пүчинкәнең исеме булып калу ихтимал. Менә инде ике гасырдан артык минем туган авылым Палагай исемен (топонимын) югалтмый. Хәзерге заманда Палагайны саф татар авылы дип әйтүе кыенрак, чөнки бирегә бисермән, удмурт, рус, украина һәм башка милләтләре килеп калганнар.

**А. Галеев, пенсионер**

Перевод на татарский I Р.З. Маратовой I